**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
05.08.2024

**КАРАР**
№ 536

**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 29 августындагы 401 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында «14.08.2018 ел, №665 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 18.06.2024 ел, №434 карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 29.08.2018 ел, №401 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары һәм аерым типка карамаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (1 нче кушымтада) расларга.

1.2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә, яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларына түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (2 нче кушымта).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына М.Д. Храменковага йөкләргә.

Җитәкче А.А. Гасыймов